| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.02.2021 Балык Бистәсе ш.т.п. №30пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында" 2013 елның 23 сентябрендәге 202пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елның 18 декабрендәге уртак коллегиясенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча беркетмә йөкләмәсен үтәү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 202пи номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 06.02.2014 № 17 пи, 20.02.2014 № 28 пи, 25.02.2015 № 61пи, 30.10.2015 № 299пи, 11.05.2016 № 68пи, 01.03.2017 ел, № 38пи, № 25.01.2018 ел, № 13пи,, 18.09.2009 ел, № 278пи, № 11.01.2020 ел, № 08пи карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) 2.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле «и» абзацы өстәргә:

"и) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында салым органының белешмәсе (ләре)".

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының

хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов